СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Решение** **Карар**

№ 12-6 от « 14 » апреля 2026 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының кайбер карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

“Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, “Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәреш кертү һәм аларны үз көчләрен югалтуын тану турында” Россия Федерациясе Президентының 2025 елның 31 декабрендәге 1009 номерлы Указын гамәлгә ашыру максатында, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының түбәндәге карарларын үз көчен югалтты дип танырга:

- 2017 елның 26 июлендәге “Мамадыш муниципаль районы "муниципаль берәмлегенең “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында “Мамадыш муниципаль районы” "муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чаралары тарафыннан бастырып чыгару өчен бирү тәртибен раслау турында” номерлы карары 7-18;

- 2021 елның 10 июнендәге “Цифрлы финанс активлары һәм цифрлы хокуклар турында белешмәләр тапшыру хакында һәм керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” 9-7 номерлы карары;

- 2022 елның 11 августындагы “Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакындагы аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” 11-15 номерлы карары;

2. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районы рәсми сайтында, “Интернет” мәгълүмати- коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр Порталында

0 0 0 0 27

http://mamadysh.tatarstan.ru/ веб- адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны муниципаль район Советының регламент, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Башлыгы В.И. Никитин